**Виталий Агапов җитәкләгән “ Моңлы Чаллы” җыр театры, Әниләр көненә туры китереп, шәһәрдәшләренә бүләк әзерләде. 28 ноябрь кичендә әлеге төркем үз тамашачысын Сара Садыйкова исемендәге концертлар залына “Моңлы Чаллы кичләре” дип исемләнгән юбилей концертына җыйды.**

# 15 ел да үтеп киткән




Күңелендә туган моңнарны бер бәйләмгә җыеп, тиз арада җырлар иҗат итә алу сәләтенә ия булган Бәчели малае Виталий көннәрдән бер көнне ныклы карарга килеп, туган авылы Сәвәләйдән Чаллы шәһәренә юл тота. Исәбе – талантлы яшьләрне җыйнап, үз иҗат төркемен булдыру. Нәкъ 15 ел элек “Моңлы Чаллы” театрының тарихы әнә шулай башлана. Концертта төркемнең истәлекле, кызыклы вакыйгалары театральләштерелгән тамаша аша күрсәтелде. Берничә сәгать эчендә тамашачы “Моңлы Чаллы”ның ничек оешуын, танылуын тагын бер кат күз алдыннан үткәрде. Эстрада җырларын башкару белән генә чикләнмичә, һәр концерт программасында төп игътибарны халык җырларын башкаруга юнәлткәнгә, театр тиз арада тамашачы күңелен яулады. Концертта төркемнең иң беренче җырчылары да катнашты. Әйе, бирегә килеп иҗади чыныгу алган җырчыларның берсе дә югалып калмаган, һәрберсе танылып, иҗат тормышында үз урыннарын тапканнар. Шуңа да Виталий Агаповны “Остаз!” дип, ә театрны – җыр мәктәбе, дип атап йөртәләр. Үзе кабызган “йолдызлар” белән рәттән чыгып җырлаучы (инде бу юлысы ак төстәге кәчтүм-чалбарына килешле ак эшләпәдән) Виталий Агаповны тамашачы алкышларга күмде. “Җырлап яшәргә язсын!” дип теләделәр театрның дуслары юбилярларны котлап.

Бәйрәм кичәсе өч сәгать ярымга сузылса да, бер мизгел булып, сизелми дә үтте. Композитор-башкаручы, күп җырлар авторы, Татарстанның атказанган артисты Виталий Агапов юбилей уңаеннан иҗат иткән ”15 ел да үтеп киткән” исемле җырын тамашачы чын мәгънәсендә бәйрәм күчтәнәче итеп кабул итте.

**Г. ЕГОРОВА.**